| | |
|---|---|
| СОВЕТ КРЫМ-САРАЙСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ БАВЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БАУЛЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КЫРЫМ-САРАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ |

РЕШЕНИЕ КАРАР

02.11.2015 ел Кырым-Сарай авыл №13

Кырым-Сарай авыл җирлегенең
2016 елга бюджеты турында

Кырым-Сарай авыл җирлеге Советы карары:

1 Статья 1.

1. 2016 елга Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетының төп характеристикаларын расларга:

1) Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты керемнәренең гомуми күләме 4732,4 мең сум.;

2) Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының гомуми күләме 4732,4 мең сум.;

3)Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты кытлыгы 0 мең сум.

2. 2016 елга Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларын әлеге карарның 1 нче кушымтасы нигезендә расларга.

2 Статья

2017 елның 1 гыйнварына Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетының бурыч йөкләмәләре буенча Эчке муниципаль бурычның иң югары чиген 0 мең сум күләмендә расларга, шул исәптән 0 мең сум муниципаль гарантияләр буенча.

2. 2016 елда Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетының муниципаль бурычының иң чик күләмен билгеләргә.

3 Статья

Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетында әлеге карарның 2 нче кушымтасы нигезендә 2016 елга фаразланган керем күләмен исәпкә алырга.

4 Статья

1. 3 нче кушымта нигезендә Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты керемнәренең Баш администраторлары исемлеген расларга.

2. 4 нче кушымта нигезендә Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганакларының Баш администраторлары исемлеген расларга.

5 Статья

1. Әлеге карарга 5 нче кушымта нигезендә 2016 елга Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасын расларга.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының " 2016 елга Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджеты чыгымнары классификациясенең бүлекләре һәм бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм төркемнәре буенча бюджет ассигнованиеләрен әлеге карарга 6 нчы кушымта нигезендә бүлүне расларга.

3.2016 елга ачык норматив йөкләмәләрне үтәү өчен Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләмен 0 мең сум күләмендә расларга.

6 Статья

1. Җирлек бюджетыннан Баулы муниципаль районы бюджетына күчерелергә тиешле башка бюджетара трансфертларның күләмен раслау, җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча төзелгән килешүләр нигезендә, 2016 елга авыл халкын мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү һәм ял итү өчен шартлар тудыру чараларын тәэмин итү өчен 2444 мең сум күләмендә җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен гамәлгә ашыру өчен.

2. 2016 елда Баулы муниципаль районы бюджетына әлеге статьяда каралган бюджетара трансфертлар ай саен тигез өлешләр белән гамәлгә ашырыла дип билгеләргә кирәк.

7 Статья

Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган бюджет тәэмин ителешен тигезләүгә 2016 елда 2292,9 мең сум күләмендә дотацияләрне Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетында расларга.

8 Статья

Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләрне Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетында 2016 елда авыл җирлекләре бюджетларына 1,7 мең сум күләмендә расларга.

9 Статья

2016 елда хәрби комиссариатлар булмаган территорияләрдә беренчел хәрби исәпкә алу өчен Баулы муниципаль районы бюджетыннан алына торган субвенцияләрне Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетында расларга.

10 Статья

1. Җирле үзидарә органнары 2016 елда муниципаль хезмәткәрләр, бюджет өлкәсе учреждениеләре һәм башка оешмалары хезмәткәрләре санын арттыруга, шулай ук аларны карап тотуга киткән чыгымнарны арттыруга китерә торган карарлар кабул итәргә хокуклы түгел.

11 Статья

Кырым-Сарай авыл җирлеге башкарма комитеты исеменнән төзелгән товарлар, эшләр башкару, хезмәт күрсәтүгә муниципаль контрактлар 2015 елда әлеге муниципаль контрактлар шартлары нигезендә түләнергә тиешле муниципаль контрактлар өчен файдаланылмаган бюджет ассигнованиеләренең калдыгы суммасыннан артмаган күләмдә 2016 елда Кырым-Сарай авыл җирлеге башкарма комитеты тиешле карар кабул иткән очракта, күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыруга юнәлдерелә.

12 Статья

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының казначылык органнары төзелгән килешүләр нигезендә Кырым-Сарай авыл җирлеге бюджетын үтәү буенча аерым функцияләрне гамәлгә ашыралар.

13 Статья

1. Әлеге карарны мәгълүмат стендында халыкка җиткерергә һәм Кырым-Сарай авыл җирлегенең рәсми сайтында «Интернет»мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

2. Әлеге карар 2016 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

Башлык, Совет Рәисе
Кырым-Сарай авыл җирлеге башлыгы Е.М. Зелепугина